Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең
Уразай торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 31 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең Уразай торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1.«I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Салагыш авыл җирлегенең Уразай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән шулай ук даими рәвештә бер елдан артык яшәүче, балигъ булган һәр гражданга 2020 нче елда үзарасалымны 350 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-Уразай авылының Ленин урамы юлларына вак таш җәю һәм ремонт ясау.

- Уразай авылы урамнарын кардан чистарту.

- Уразай авылында кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы коры яшел үсентеләрне кисү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Салагыш авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarctan.ru Татарстан Республикасы муниципаль , берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе М. М. Мөхәммәдиев